ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422150

Яшьлек ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru


Постановление | Карар

“22 ” декабрь 2017 ел | № 17

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән теререкөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән теререкөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны урнаштыру түбәндәгечә башкарыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Дүсмәт авылы, Яшьләр урамы, 17 йорт;

2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы Иске Комазан авылы,Ушмы урамы,20 йорт;

3. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Комазан башы авылы, Үзәк урам, 17 йорт,;

4. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Акман авылы, Ленин урамы, 34 йорт;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарында урнаштырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге
башкарма комитеты житәкчесе /О.Н. Павлов/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Башкарма комитетының
22 декабрь 2017 ел, № 17 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге**

| № | Көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге адреслары |
|---|---|
| 1. | 422150, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Дүсмәт авылы, Татарстан урамы, 86 йорт (ярдәмче бина). |